# КАРАР

## Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлеге составына керүче Савгачево авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

25.11.2025 ел № 4

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы 24 статьясы, «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Урмандеево авыл җирлеге Советы 05.11.2019 елгы 96 номерлы карарына таянып 21.11.2025 ел түбәндәге мәсьәлә буенча узган халык җыены беркетмәсе төзелде: «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлеге Савгач авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Федерациясенең махсус операцияләрдә катнашучы хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

**1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**
торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу, ташу, юлларны кышкы карап тоту шартнамә буенча эшләр өчен түләү )

**2) күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**
- урамнарны яктырту җайланмасы (торак пункт чикләрендә урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен товарлар сатып алу);

«РИЗА» «КАРШЫ» «ТЫЕЛДЫМ”

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 314 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 157 граждан кертелде.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
- «Риза»- 157 катнашучы тавыш бирде;
- «Каршы» - 0 катнашучы тавыш бирде;
- «Тыелдым»-0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены КАРАРы:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы районы Урмандеево авыл җирлеге Савгач торак пунктында гражданнар җыенын узды, нәтиҗәләре – дөрес дип таныирга.

2. Мәсьәлә буенча карарны кабул дип таныирга: «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлеге Савгач авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Федерациясенең махсус операцияләрдә катнашучы хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

**1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу, ташу, юлларны кышкы карап тоту шартнамә буенча эшләр өчен түләү )

**2) күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- урамнарны яктырту җайланмасы (торак пункт чикләрендә урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен товарлар сатып алу);

3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районы рәсми сайтында http://aksubayevo.tatar.ru урнаштырырга һәм рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/, Урмандеево авыл җирлеге мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга .

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Урмандеево авыл җирлеге башлыгы В.З.Николаев